ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2018 г.Мензелинск № 1384

08.02.2003 елдагы “Балалар сәнгать мәктәбе” дәүләт учреждениесен булдыру турындагы №55 Карарына үзгәрешләр кертү турында

08.10.2018 елда кабул ителгән “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль казна учреждениеләре уставларына (нигезләмәләргә), мәнфәгатьләр каршылыгына китергән һәм китерергә мөмкин булган хезмәт вазифаларын башкарганда шәхси кызыксынучанлык килеп чыгу турында хәбәр итү бурычын билгеләүче тиешле учреждение (предприятие) җитәкчеләре һәм анда эшләүчеләр тарафыннан хезмәт килешүләренә мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу мәсьәләләрен җайга салучы үзгәрешләр кертү турында”гы №1136, шулай ук 25.12.2008 елдагы “Коррупциягә каршы тору турында”гы №273-ФЗ Федераль Законы нигезендә, Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәренең “Балалар сәнгать мәктәбе” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертергә.

1.1.”Учреждение белән идарә итү” V бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге 5.19 пунктын өстәргә: “Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу”.

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәренең “Балалар сәнгать мкәтәбе” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе директоры О.В.Красннованы Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәренең “Балалар сәнгать мкәтәбе” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертүне уздыру буенча вәкаләтле итеп билгеләргә.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Г.Бикеевага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Г.Гатина.